Мирзанур Вәлиев

## КИЛӘЧӘККӘ ЫШАНЫЧ БЕЛӘН (ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНДА БЕЛЕМ-ТӘРБИЯ БИРҮ ДОКТРИНАСЫ ТУРЫНДА)

ТАТАР ИЛЕ №26 (387), июнь, 2000 ел.

Татарстанда, Бөтен Россиядәге кебек, хәзерге шартларда белем-тәрбия бирү эшләренең аеруча максатка ярашлы юлларын эзләү бара. Элек үнитар дәүләт мәнфәгатьләренә хезмәт иткән мәгариф системасы бөтен илдә бертөрле булуы белән аерылып торды. Хәзер исә ул белем-тәрбия бирү юлын сайлау шартларында булып чыкты. Соңгы елларда Россиядә һәм Татарстанда барлыкка килгән күп кенә концепцияләрдә (шул исәптән татар милли мәгарифен үстерү концепциясендә) мәгариф эшләрен камилләштерүнең төрле алымнары һәм вариантлары бәян ителде. Әмма Татарстан Республикасы күп нәрсәләрдә тел йотылуга, милли үзенчәлекләрне, шәхеснең халык-гуманистик концепцияләрен бетерүгә урын булмаган, башкаларга охшамаган цивилизацияле, хокукый җәмгыятькә үз юлын тота; халык һәм республиканың икътисади, интеллектуаль һәм рухи-әхлакый потенциалы иң зур үсешкә ирешәчәк. Шуны истә тотып, Татарстан Республикасы Президенты Минтимер Шәймиев бер чыгышында: "Татарстанның үзенең мәгариф доктринасы булырга тиеш", – дип әйткән иде.

Доктрина – югары теория ул. Элек Россиядә дә, Татарстанда да мәгарифнең шундый фәнни нигезләнгән доктринасы беркайчан да булмады. Демократияләштерү, фикер һәм алымнар төрлелеге үскән шартларда аның зарурлыгы аеруча көчле Татарстан Республикасында белем-тәрбия системаларын үстерүнең милли доктринасын эшләгәндә Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы кануннарының төп положениеләре исәпкә алынды, чөнки мәгариф киңлеге, берлеге шуны таләп итә.

Доктрина шул мәгънәдә "милли" дип аталган: а) гомумдәүләт; б) аерым халыкларның мәгариф ихтыяҗларын гамәлгә ашырылуын күздә тотканга, чөнки Татарстан элек-электән яшәгән күпләрнең Ватаны булып тора.
Әлеге доктрина "Татарстан Республикасында милли мәгарифнең концептуаль нигезләре"нә (Проект) каршы килми, ә, киресенчә, бу проектны мәгариф хезмәткәрләренең Бөтентатар Корылтаенда (Казан, 2000 ел) әйтелгән фикерләрне югарырак, перспективалы, фәнни дәрәҗәгә күтәрә.

Атналык гомумтатар газеталары "Татар иле" һәм "Татарские края"ның 23, 24, 25 (2000 ел) саннарында татар һәм рус телләрендә басылып чыккан Татарстан Республикасында белем-тәрбия системаларын үстерүнең Милли доктринасы турында Татарстан Республикасы Мәгариф министрлыгы, мәгариф хезмәткәрләренең квалификацияләрен күтәрү институты, Казан шәһәре Мәгариф идарәсе, Татарстан Фәннәр академиясе, уку йортлары, "Мәгариф" бөтентатар ассоциациясе, шулай ук гаммәви коммуникация чаралары вәкилләре катнашында күп тапкыр фикер алышынды. Аларның тәкъдиме проектка төзәтмәләр керткәндә искә алынды. Бу доктринаны эшләү буенча авторлар коллективының бөтен кызыксынучы кешеләргә һәм оешмаларга өстәмәләр кертүдә ачыклык һәм мөмкинлек бирүен күрсәтә, ә ул анда бәян ителгән положениеләрнең тормышчанлыгын һәм реальлеген көчәйтә.

Доктрина бер үк вакытта матур, кызыктырырлык шигарьләр белән чикләнергә тиеш түгел. Мәгариф системасында тулаем һәм, өлешчә, хәзерге татар милли мәгарифендә хәл ителмәгән мәсьәләләр бар, алар теория һәм практиканы үстерү өчен конкрет чаралар исемлеген бәян итүне таләп итәләр. Мәсәлән, доктринада санап кителгән кайбер юнәлешләр буенча концепцияләр, күз алдында тотылганча,

галим-педагогларның гына түгел, бәлки мәгариф бүлекләре, методистлар һәм укытучыларның киң катнашында эшләнәчәк.

Татарстан Фәннәр академиясе Тарих институты Милли мәгариф тарихы һәм теориясе үзәге фәнни коллективы тарафыннан беренче тапкыр эшләнгән Татарстан Республикасында белем-тәрбия системаларын үстерүнең Милли доктринасы белем-тәрбия бирүне төбәк-ләштерү шартларында педагогик фикерне һәм теорияне тагын да интенсиврак үстерүгә хезмәт итәр, Татарстанда мәгарифне үстерүне максатка ярашлы системалы планлаштыруга яңа импульс бирәчәк; ә гамәли хезмәткәрләр өчен көндәлек эшләрендә бик кирәкле ориентир булачак.

Әйтергә кирәк, Татарстан белем-тәрбия доктринасы Россиянекенә караганда иртәрәк эшләнде. Димәк, чынлап та: "Фәндә провинцияләр юк"; һәм бездә, Татарстанда да, һәм татар халкы төпләнеп яши торган төбәкләрдә) шактый зур, әмма дәүләт сәясәтендә әлегә тулысынча файдаланылмый торган интеллектуаль потенциал бар.
Эшләнгән доктрина белем-тәрбия бирүнең иң актуаль проблемаларын хәл итүгә юнәлеш тота. Киләчәктә аның Татарстан Республикасында мәгарифне, белем-тәрбия системаларын үстерүнең аерым юнәлешләре буенча практик концепцияләрне һәм дәүләт сәясәтен хәзерләүдә нигез булуы мөмкин.